ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хисап палатасына 2022 елда түбәндәгеләрне үткәрүне йөкләргә:

2020 – 2021 елларда һәм 2022 елның үткән чорында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге чараларны, инвалидларны эшкә урнаштыруны тәэмин итүне оештыру чараларын да кертеп, гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелегенә аудит;

2019 – 2021 елларда урта һөнәри белем бирү системасын үстерүгә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелегенә аудит.

2. Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2022 елның IV кварталында тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2022 елның 10 феврале
№ 1338-VI ДС